ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.11.2024 Олы Кайбыч ав. № 413

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затларының исемлеген раслау хакында» 2019 елның 17 декабрендәге 550 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 октябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затларының исемлеген раслау хакында» 2019 елның 17 декабрендәге 550 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 23 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «23 | 3.16 статья. Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан)файдалану тәртибен бозу | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече.» |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров